Хәмидуллина, Р. Г. Үгезне җик, кино куярга барабыз / Р. Г. Хәмидуллина // Гыйбрәтханә. – 2025. - №5. – Б. 4-6



*Редакциягә өлкән буын күргән авырлыклар, алар тормышындагы гыйбрәтле, кызыклы хәлләр турында язмалар күп килә. Бүген без шуларның берсен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.*



# Үгезне җик, кино куярга барабыз

***Өйдә – гел җылылык, елмаю, тыныч кына бер-береңбелән аралашу. Инде гаилә тормышының кырык җиде елы артта калса да, бер күз карашыннан ук аңлашып, бер-берсенә булган мәхәббәт җепләрен саклап яшиләр алар. Язмам – 96 яшен тутырып килүче Зөфәр Сәгыйтов гаиләсе турында.***

Зөфәр Ярулла улы Сәгыйтов 1929 елның 12 августында Чаллы (хәзерге Тукай) районы Биклән авылында туган. Себернең алтын приискасына барып, ике ат йөге белән әйберләр алып кайткан атаклы Җиһанша бабай оныгы ул. Бабасы бик эшчән кеше була. Себердә көмне тәнгә ялгап эшли, һәр тиенен җыеп бара. Күңеле гел туган якларына ашкына. Ике йөк әйбер белән берзаман Җиһанша авылга кайтып керә. Бөтен халык шакката. Бүгенге көндә дә Зөфәр абыйлар өендә немец физгармуны белән француз сәгате саклана. "Нәрсә ул физгармун?" – дип сорагач, кечкенә орган, дип аңлатты Зөфәр абый. Хатыны Людмила ханым: "Зөфәр аны карап, чистартып тора, шуңа үз тавышын югалтмый", – дип уйнап та күрсәтте. "Алып кайткан әйберләр арасында карап торырлык чәй чашкелары да бар иде. Әбием Гайшәбикә бик матур киенеп йөрде. Соклангыч белемле иде. Авылга урыс кешеләре килсә, телләрен әби тәрҗемә итеп биргән. Ул туксан өч яшенә кадәр яшәде", – дип сөйләде Зөфәр абый.

Җиһаншаның балалары күрше Бәтке авылындагы урыс мәктәбендә укыйлар. Җәй көннәрендә ишегалды клуб ролен уйный. Йорт хуҗасы төрле уен коралларында уйный. Тәрәзәсен ачып куеп, читтән алып кайткан граммофонын куша. Җыр, бию, уеннар граммофон көйләре астында башкарыла. Капка төбенә бөтен авыл халкы җыела. Авыл осталары, өйдәге җиһазларны күреп, үзләре дә шуларга охшаш карават, өстәл, урындыклар ясый башлыйлар.

Читтә йөреп, күпне күреп кайткан Җиһанша бик миһербанлы, игелекле кеше була. Авыл халкына ярдәмен, булышлыгын күрсәтеп яши. Раскулачивание башлангач, бабайга да кагылмый калмыйлар. Шул вакытта авыл халкы, бердәм булып, Җиһаншаны яклап кала.

Зөфәр, Җиһанша бабайның оныгы, гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә. Аннан соң тагын бер кыз, бер малай өстәлә. Аның балачагы эш белән үтә, уенчыклар булмау сәбәпле, машина, тракторларны ул агачтан, тимердән үзе ясый.

– Минем әти Ярулла Бикләнгә беренче трактор алып кайткан кеше, – дип сөйләп китте Зөфәр абый. – Утызынчы еллар башында Рәсәйдә ике трактор заводы эшли башлый. Беренчесе – Сталинградта (халык телендә СТЗ дип йөртелә), икенчесе – Харьковта (ХТЗ). Харьков трактор заводыннан баржаларда, Идел, Кама елгалары буйлап, бу якларга да тракторлар кайта. Яңа тракторны алырга Ярулланы җибәрәләр. Ул таң атып килгәндә авылга кайтып керә. Ят тавыштан куркуга төшкән халык урамга чыга. Әтинең: "Басулар сукалар өчен трактор алып кайттым", – дигәнен ишеткәннән соң гына тынычланалар.

Батыр, тәвәккәл бер-ике егетне трактор йөртергә өйрәткәч, Ярулланы утыз чакрым ераклыктагы "Кызыл Чапчак" бистәсенә, МТСка инженер итеп җибәрәләр. Эшчеләр өчен төзелгән йорттан фатир алгач, гаиләсен дә алып китә ул. Зөфәр әтисенә ияреп эшкә йөри. Алар техниканы язгы кыр эшләренә әзерлиләр. Башта әтисе эшләгәнне игътибар белән күзәткән Зөфәр, берзаман үзе дә машина, тракторлар ремонтлый башлый. Тормыш үз җаена баргандা, халык дошманы дип, МТС директорын, механикны, инженер булып эшләүче Ярулланы кулга алалар. Тикшерү берничә айга сузыла. Гаиләсе, балалары өчен борчылу, сәламәтлеге нык какшау Ярулланы сигез ай дигәндә кабергә тыга.

Шул ук елда, эш күрсәткечләре буенча, МТСның республикада икенче урын алуы билгеле була. Директор да, механик та, акланып, исән-имин МТСка әйләнеп кайталар. Ярулла гаиләсенә йортны бушатырга кушалар. Хатын биш баласы белән кире Бикләнгә кайта. Җиһанша бабай бу вакытта инде мәрхүм була. Зөфәр авыл мәктәбендә өченче-дүртенче классларда укый. Әнкәсе Мәликәгә ишле гаиләне берүзе алып бару авыр була. Аның Чаллыга барып эшкә урнашасы килә. Эш белешеп кайткач, авыл советыннан рөхсәт алып, шәһәргә күченәләр.

Җыелган күпмедер акчасына Мәликә йорт сатып ала.

– Мин әнинең эшсез торганын хәтерләмим. Ул тегүче иде, – дип искә ала Зөфәр абый.

Үсмер егет Муллануp Вахитов исемендәге мәктәптә җиденче сыйныфны тәмамлаганда елны сугыш башлана. Әниләренә солдатлар өчен киемне өйдә тегәргә рөхсәт итәләр. Ул көненә өчәр норма үти. Зөфәр дә, әнисенә булышып, тегү тегә. Гаиләне ачлыктан алып калган "Зингер" машинасы әле дә исән.

– Машина тегәме? – дип сорагач, Людмила ханым:

– Әйе, үз хутында әле ул... Зөфәр яшьрәк чагында миңа куплмак, юбкалар да тегеп киндертте, – дип елмаеп куйды.

Малика апа балаларын эшләп яшәргә өйрәтеп үстерә. 87 яшендә бакыйлыкка күчә.

Чаллы кинотеатры директоры Иван Агафонов физика фәненнән "5"ле билгеләренә генә укучы өч малайны сайлап ала. Алар арасында җиденче классны тәмамлаган Зөфәр дә була. Иван Григорьевич: "Тәзәтә аласыңмы", – дип, аңа ватык киноаппаратны күрсәтә. Зөфәр аны сүтеп, чистартып, ватык частьларне кулдан ясап, ун көн эчендә аппаратны яңадан җыя. Шул көннән башлап, Иван Григорьевич, егетне хөрмәт итеп, аңа "иптәш Сәлыйтов" дип эндәшә башлый.

Киномеханиклыкка айлык курслар үткәч, Зөфәрне җитәкче итеп куялар. Алар Чаллы районы буенча авылдан-авылга кино күрсәтеп йөриләр. Шакирҗанов Мидхәт белән бергә Сарманда да кино күрсәтү җайланмасы урнаштыралар әле. "Чапаев" киносы гел тулы залларда үтә. "Радуга", "Два бойца", "Парень из нашего города", "Свинарка и пастух", "Истребитель", "Она защищает Родину" һәм башкаларны халык кат-кат карый. Бер авылдан икенчесенә күчкәндә, ат булмаганда, үгез, сыер җигеп йөриләр.

– Бервакыт күрше авылга барабыз дип чыксак, үгезләр урынына өч яшь хатын җигелгән иде. Алар – алдан, без икәү арттан этеп барабыз. Беребезне-беребез уздырып мәзәкләр сөйләп, күрше авылга барып җиткән сизелмәде дә, – дип, искә ала Зөфәр абый. – Үгезләр белән кызык хәлләр күп булды инде ул. Беркөн шулай үгез җигелгән арба белән авылга килеп кердек. Этләр өрә башлауга, үгезебез торып чапты. Көчкә туктаттык. Бу малкай бер киреләнсә, хикмәт бит ул. Берзаман урыныннан кымшанмагач, бер иптәшебез, үгезнең койрыгын күтәреп, салам тыкты да, ут төртеп җибәрде. Чаба бичара, тынып булмый. Чана авып, кино әрҗәләре белән бергә көртка барып төштек. Үгез читәндә асылынып калды. Туарып җибәрүгә тагын чабарга тотынды... Сугыштан соң Чаллыда балалар йорты ачылды. "Красногвардейская" дигән урамда иде ул. Безнең күрше апа анда хисапчы булып эшли иде. Музыка коралларында уйнаучы булса, яхшы булыр иде дип, музыкант эзлиләр икән. Хисапчы апа минем аккордеонда уйнавымны әйтә. Менә, горком аша сөйләшеп, балалар йортына музыка хезмәткәре итеп күчереп куйдылар. Бер елдан армиягә алдылар.

Егет солдат хезмәтендә дә инструменталь ансамбль оештыра. Дүрт ел үтеп, офицер дәрәҗәсендә армиядә калу мөмкинлеге дә була, ләкин туган яклар үзенә тарта. Күзе җәрәхәтләнеп кайткан абыйсы Мисбах Чаллыда сәгать мастерскоенда эшли. Аннан Фирганә шәһәренә чыгып китә, кырык ел шунда яши. Олы абыйлары Мирза егерме дүрт яшендә сугышта үлә. Аның 1943 елда язган хаты, фотосы әле дә саклана. Анда: "Кадерле әнием, кадерле туганнарым һәм агай, энеләрем, әгәр дә дөньядан үтсәм, исегезгә алыгыз, хушыгыз, туганнарым. 11 март, 1943 ел", – дигән юллар бар.

Авиациядә хезмәт итеп кайткан Зөфәр Чаллы аэродромына эшкә урнаша. Ул елларда моннан самолетлар бик сирәк оча. Самолет көтеп утырган вакытларында ул күп китаплар укый. Егеткә үз эше бик ошап бетми. Ничек тә китү җаен эзли. Эштән чыгып, абыйсы чакыруы буенча Фирганәгә китә. Мисбах ул елларда мәктәптә музыка укыта. Энесен дә үз янына машиноведение укытырга урнаштыра. Аккордеонда уйнаган Зө-фәр моның белән генә чикләнми, мәдәният йортына эшкә урнаша, кичләрен биюләр оештыра. Кергән акчаның бер өлешен әнкәсенә җибәреп тора.

Өч еллап эшләгәч, егет кире Чаллыга кайтып китә. Горкомга эш сорап бара. Анда эшләүче танышы Дәүләтшин Марс, Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә музыка укытучысы юклыкны күздә тотып, шунда юллама тапшыра. Мәктәп директоры булып эшләгән Накый Әхмәтшин аны эшкә ала.

Зөфәр укучылардан өч тавышка җырлаучы хор төзи. Егет армиягә кадәр Габдрашит Нигъматуллин җитәкләгән тынлы оркестрда уйнаган була. Хорны шунда уйнаган система буенча өйрәтә. Мәктәпләр арасында смотр-конкурслар оештырыла. Бәйгегә җибәргәнче, мәктәп укытучылары хорны тыңлап карыйлар. Өч тавышка җырлауны берсе дә аңламый. Боларны чыгарып оятка калмабызмы, болардан әллә нинди тавышлар чыга бит диләр. Зөфәр, төрле дәлилләр табып, үз хорын яклап чыга, смотрда чыгыш ясарга рөхсәт ала. Алар конкурста иң соңгы булып җырлыйлар. Жюрида утырган махсус белемле егет, өч тавышка җырлаучы хорны ишетеп, таң кала, беренче урын бары тик аларга ди. Күп еллар беренче булган күрше Димитрово мәктәбенә шулай итеп, алдынгы урын эләкми. Егерме ел дәвамында мәктәп хорына тиңнәр табылмый. Шул елларда Зөфәр Алабуга культура-агарту училищесын, аннан Казан педагогия институтының музыка факультетын тәмамлый. Үзлегеннән бик күп методик дәреслекләрне өйрәнгән әзерлекле егет югары уку йортында бик җиңел укый.

Музыка укыту белән бергә, егет мәктәп ишек алдында хезмәт фәне өчен әзерләнгән йортка да җан кертә. Аны ике өлешкә бүлеп, берсендә – слесарь, икенчесендә столяр эшләре өчен кабинетлар ясый. Укучыларны үзе белгән тимер, агач эшләренә өйрәтә. Шуларга өстәп, Зөфәргә машиноведение дәресе дә укытырга туры килә. Укуны практика белән бәйләп алып бару өчен машина кирәк була. Списать ителгән бер машинаны мәктәп ишек алдына алып кайтып куялар. Бер җыелышта Зөфәр: "Мин бу машинаны җыеп чыгачакмын", – дип әйтеп ташлый. Бу сүзгә укытучылар ышанмый, елмаеп кына куялар. Чаллыда тимер җыюда эшләүче танышына запчастьлар кирәклеген әйткәч, монда бөтен нәрсә дә бар, эзләргә генә кирәк, дигән җавапны ишетеп, Зөфәр бик сөенә. Бер-ике айда машина копчәкле була. Аннан двигатель, башка детальләр үз урыннарын таба. Бер ел дигәндә, машина йөреп китә. Мәктәп өчен бу көн бәйрәмгә әйләнә. Директорны утыртып, ГАИга номер алырга машина үз юдында бара. Машина Зөфәрнең тормышында да бик булыша. Өй салырга бүрәнәләрне шуның белән алып кайта ул. Бүген яшәгән алты почмаклы өен 1963 елда үз куллары, үз проекты белән салып кертә.

Моңа кадәр дә, 1960 елда, биш кеше утырышлы аэрочана ясап, шәһәр халкын шаккатырган була. Шактый вакыт гаилә Бикләнгә шул чана белән кайтып йөри. Чаллыда зур төзелеш башлангач кына, чана-

(Ахыры 6 нчы биттә)

## ГЫЙБРӘТХАНӘ 6

(Ахыры. Башы 4-5 битләрдә)

да йөрүләрен туктаталар. Чөнки бөтен җирдә төзелеш башланып китә, чана белән авылга үтү мөмкинлекләре бетә.

– Бик уйланып эшләнгән чана иде ул. Фотосурәте калмаган шул. Кызыксынсагыз, мин аның сурәтен ясый алам, – дип елмая Зөфәр абый.

– Электросабан да ясады бит ул, – дип, Людмила ханым да әңгәмәгә кушыла. – Аның белән күп еллар бакча җирен эшкарттек, казыдык әле без...

Минем дә, үз чиратымда, китапханәнең сәнгать бүлеген бизәүче пианиноны, әдәбият тарихы музеенда урын алган балалайка, гармуннарны да Зөфәр абыйның алтын куллары төзәткәнен әйтеп үтәсем килә.

Зөфәр Сәгыйтов нинди генә эшкә алынмасын, эшен җиренә җиткереп башкарып чыга. Гаилә коруы гына бераз икенче планга күчә. Беренче тапкыр 36 яшендә өйләнә. Үз тиңен тапканчы, язмыш аны төрле яклап сыный. 1978 елда ул Людмиланы очрата. Яңа гына Түбән Кама музыка училищесын тәмамлап кайткан яшь белгеч белән ике арада, беренче күрү белән үк, мәхәббәт җепләре сузыла. Эшләре дә бергә, гаиләне дә бергә алып баралар. Берсе – хор белән дирижерлык итеп, икенчесе музыка коралында оста уйнап, бер-берсенең күңелендә урын табалар. Менә инде кырык җиде ел алар бергә гомер кичерәләр, берсен-берсе тулыландырып иҗат итәләр.

Зөфәр абыйның бер зур теләге әлегә тормышка ашмаган. Балалар, оныклар – алар өендә көтеп алынган, яраткан кунаклар. Ул нәселләрендәге барлык туганнарын, балаларын, онык-оныкчыкларын бергә җыярга хыяллана. Бүгенге көндә Сәгыйтовларның дүрт баласы, тугыз оныгы, бер оныкчыклары бар.

Балалар, оныклар "дәү әти" дип кенә торалар. Аның янәшәсендәге мөлаем, сөйкемле, игътибарлы ханымга, якын итеп, "дәү әнкебез" диеп дәшәләр. Шулай булсын, бергә аңлашып яшәүләргә ни җитә? Сәгыйтовлар гаиләсе бәхетле, матур тормыш юлы узалар. Күпсенмә, Ходаем, бу бәндәләреңнән шушы бәхетне дип кабатлыйм.

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА, Чаллы.**

***Өйдә – гел җылылык, елмаю, тыныч кына бер-берең белән аралашу. Инде гаилә тормышының кырык җиде елы артта калса да, бер күз карашыннан ук аңлашып, бер-берсенә булган мәхәббәт җепләрен саклап яшиләр алар. Язмам – 96 яшен тутырып килүче Зөфәр Сәгыйтов гаиләсе турында.***

***Редакциягә өлкән буын күргән авырлыклар, алар тормышындагы гыйбрәтле, кызыклы хәлләр турында язмалар күп килә. Бүген без шуларның берсен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.***



# Үгезне җик, кино куярга барабыз

Зөфәр Ярулла улы Сәгыйтов 1929 елның 12 августында Чаллы (хәзерге Тукай) районы Биклән авылында туган. Себернең алтын приискасына барып, ике ат йөге белән әйберләр алып кайткан атаклы Җиһанша бабай оныгы ул. Бабасы бик эшчән кеше була. Себердә көнне төнгә ялгап эшли, һәр тиенен җыеп бара. Күңеле гел туган якларына ашкына. Ике йөк әйбер белән берзаман Җиһанша авылга кайтып керә. Бөтен халык шакката. Бүгенге көндә дә Зөфәр абыйлар өендә немец физгармуны белән француз сәгате саклана. "Нәрсә ул физгармун?" – дип сорагач, кечкенә орган, дип аңлатты Зөфәр абый. Хатыны Людмила ханым: "Зөфәр аны карап, чистартып тора, шуңа үз тавышын югалтмый", – дип уйнап та күрсәтте. "Алып кайткан әйберләр арасында карап торырлык чәй чәшкеләре дә бар иде. Әбием Гайшәбикә бик матур киенеп йөрде. Соклангыч белемле иде. Авылга урыс кешеләре килсә, телләрен әби тәрҗемә итеп биргән. Ул туксан өч яшенә кадәр яшәде", – дип сөйләде Зөфәр абый.

Җиһаншаның балалары күрше Бәтке авылындагы урыс мәктәбендә укыйлар. Җәй көннәрендә ишегалды клуб ролен уйный. Йорт хуҗасы төрле уен коралларында уйный. Тәрәзәсен ачып куеп, читтән алып кайткан граммофонын куша. Җыр, бию, уеннар граммофон көйләре астында башкарыла. Капка төбенә бөтен авыл халкы җыела. Авыл осталары, өйдәге җиһазларны күреп, үзләре дә шуларга охшаш карават, өстәл, урындыклар ясый башлыйлар.

Читтә йөреп, күпне күреп кайткан Җиһанша бик миһербанлы, игелекле кеше була. Авыл халкына ярдәмен, булышлыгын күрсәтеп яши. Раскулачивание башлангач, бабайга да кагылмый калмыйлар. Шул вакытта авыл халкы, бердәм булып, Җиһаншаны яклап кала.

Зөфәр, Җиһанша бабайның оныгы, гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә. Аннан соң тагын бер кыз, бер малай өстәлә. Аның балачагы эш белән үтә, уенчыклар булмау сәбәпле, машина, тракторларны ул агачтан, тимердән үзе ясый.

– Минем әти Ярулла Бикләнгә беренче трактор алып кайткан кеше, – дип сөйләп китте Зөфәр абый. – Утызынчы еллар башында Рәсәйдә ике трактор заводы эшли башлый. Беренчесе – Сталинградта (халык телендә СТЗ дип йөртелә), икенчесе – Харьковта (ХТЗ). Харьков трактор заводыннан баржаларда, Идел, Кама елгалары буйлап, бу якларга да тракторлар кайта. Яңа тракторны алырга Яруллаunion жибәрәләр. Ул таң атып килгәндә авылга кайтып керә. Ят тавыштан куркуга төшкән халык урамга чыга. Әтинең: "Басулар сукалар өчен трактор алып кайттым", – дигәнен ишеткәннән соң гына тынычланалар.

Батыр, тәвәккәл бер-ике егетне трактор йөртергә өйрәткәч, Яруллаunion утыз чакрым ераклыктагы "Кызыл Чапчак" бистәсенә, МТСка инженер итеп җибәрәләр. Эшчеләр өчен төзелгән йорттан фатир алгач, гаиләсен дә алып китә ул. Зөфәр әтисенә ияреп эшкә йөри. Алар техниканы язгы кыр эшләренә әзерлиләр. Башта әтисе эшләгәнне игътибар белән күзәткән Зөфәр, берзаман үзе дә машина, тракторлар ремонтлый башлый. Тормыш үз җаена баргында, халык дошманы дип, МТС директорын, механикны, инженер булып эшләүче Яруллаunion кулга алалар. Тикшерү берничә айга сузыла. Гаиләсе, балалары өчен борчылу, сәламәтлеге нык какшау Яруллаunion сигез ай дигәндә каберге тыга.

Шул ук елда, эш күрсәткечләре буенча, МТСның республикада икенче урын алуы билгеле була. Директор да, механик та, акланып, исәнимин МТСка әйләнеп кайталар. Ярулла гаиләсенә йортны бушатырга кушалар. Хатын биш баласы белән кире Бикләнгә кайта. Җиһанша бабай бу вакытта инде мәрхүм була. Зөфәр авыл мәктәбендә өченче-дүртенче классларда укый. Өнкәсе Мәликәгә ишле гаиләне берүзе алып бару авыр була. Аның Чаллыга барып эшкә урнашасы килә. Эш белешеп кайткач, авыл советыннан рөхсәт алып, шәһәргә күченәләр.

Җыелган күпмедер акчасына Мәликә йорт сатып ала.

– Мин әнинең эшсез торганын хәтерләмим. Ул тегүче иде, – дип искә ала Зөфәр абый.

Үсмер егет Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә җиденче сыйныфны тәмамлаган елны сугыш башлана. Әниләренә солдатлар өчен киемне өйдә тегәргә рөхсәт итәләр. Ул көненә өчәр норма үти. Зөфәр дә, әнисенә булышып, тегү тегә. Гаиләне ачлыктан алып калган "Зингер" машинасы әле дә исән.

– Машина тегәме? – дип сорагач, Людмила ханым:

– Әйе, үз хутында әле ул... Зөфәр яшьрәк чагында миңа күлмәк, юбкалар да тегеп кидертте, – дип елмаеп куйды.

Мәликә апа балаларын эшләп яшәргә өйрәтеп үстерә. 87 яшендә бакыйлыкка күчә.

Чаллы кинотеатры директоры Иван Агафонов физика фәненнән "5"ле билгеләренә генә укучы өч малайны сайлап ала. Алар арасында җиденче классны тәмамлаган Зөфәр дә була. Иван Григорьевич: "Төзәтә аласыңмы", – дип, аңа ватык киноаппаратны күрсәтә. Зөфәр аны сүтеп, чистартып, ватык частьләрне кулдан ясап, ун көн эчендә аппаратны яңадан җыя. Шул көннән башлап, Иван Григорьевич, егетне хөрмәт итеп, аңа "иптәш Сәгыйтов" дип эндәшә башлый.

Киномеханиклыкка айлык курслар үткәч, Зөфәрне җитәкче итеп куялар. Алар Чаллы районы буенча авылдан-авылга кино күрсәтеп йөриләр. Шакирҗанов Мидхәт белән бергә Сарманда да кино күрсәтү җайланмасы урнаштыралар әле. "Чапаев" киносы гел тулы залларда үтә. "Радуга", "Два бойца", "Парень из нашего города", "Свинарка и пастух", "Истребитель", "Она защищает Родину" һәм башкаларны халык кат-кат карый. Бер авылдан икенчесенә күчкәндә, ат булмаганда, үгез, сыер җигеп йөриләр.

– Бервакыт күрше авылга барабыз дип чыксак, үгезләр урынына өч яшь хатын җигелгән иде. Алар – алдан, без икәү арттан этеп барабыз. Беребезне-беребез уздырып мәзәкләр сөйләп, күрше авылга барып җиткән сизелмәде дә, – дип, искә ала Зөфәр абый. – Үгезләр белән кызык хәлләр күп булды инде ул. Беркөн шулай үгез җигелгән арба белән авылга килеп кердек. Этләр өрә башлауга, үгезебез торып чапты. Көчкә туктаттык. Бу малкай бер киреләнсә, хикмәт бит ул. Берзаман урыныннан кымшанмагач, бер иптәшебез, үгезнең койрыгын күтәреп, салам тыкты да, ут төртеп җибәрде. Чаба бичара, тыен булмый. Чана авып, кино әрҗәләре белән бергә көрткә барып төштек. Үгез читәндә асылынып калды. Туарып җибәрүгә тагын чабарга тотынды... Сугыштан соң Чаллыда балалар йорты ачылды. "Красногвардейская" дигән урамда иде ул. Безнең күрше апа анда хисапчы булып эшли иде. Музыка коралларында уйнаучы булса, яхшы булыр иде дип, музыкант эзлиләр икән. Хисапчы апа минем аккордеонда уйнавымны әйтә. Мине, горком аша сөйләшеп, балалар йортына музыка хезмәткәре итеп күчереп куйдылар. Бер елдан армиягә алдылар.

Егет солдат хезмәтендә дә инструменталь ансамбль оештыра. Дүрт ел үтеп, офицер дәрәҗәсендә армиядә калу мөмкинлеге дә була, ләкин туган яклар үзенә тарта. Күзе җәрәхәтләнеп кайткан абыйсы Мисбах Чаллыда сәгать мастерскоенда эшли. Аннан Фирганә шәһәренә чыгып китә, кырык ел шунда яши. Олы абыйлары Мирза егерме дүрт яшендә сугышта үлә. Аның 1943 елда язган хаты, фотосы әле дә саклана. Анда: "Кадерле әнием, кадерле туганнарым һәм агай, энеләрем, әгәр дә дөньядан үтсәм, исегезгә алыгыз, хушыгыз, туганнарым. 11 март, 1943 ел", – дигән юллар бар.

Авиациядә хезмәт итеп кайткан Зөфәр Чаллы аэродромына эшкә урнаша. Ул елларда моннан самолетлар бик сирәк оча. Самолет көтеп утырган вакытларында ул күп китаплар укый. Егеткә үз эше бик ошап бетми. Ничек тә китү җаен эзли. Эштән чыгып, абыйсы чакыруы буенча Фирганәгә китә. Мисбах ул елларда мәктәптә музыка укыта. Энесен дә үз янына машиноведение укытырга урнаштыра. Аккордеонда уйнаган Зө-фәр моның белән генә чикләнми, мәдәният йортына эшкә урнаша, кичләрен биюләр оештыра. Кергән акчаның бер өлешен әнкәсенә җибәреп тора.

Өч еллап эшләгәч, егет кире Чаллыга кайтып китә. Горкомга эш сорап бара. Анда эшләүче танышы Дәүләтшин Марс, Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә музыка укытучысы юклыкны күздә тотып, шунда юллама тапшыра. Мәктәп директоры булып эшләгән Нәкый Әхмәтшин аны эшкә ала.

Зөфәр укучылардан өч тавышка җырлаучы хор төзи. Егет армиягә кадәр Габдрәшит Нигъмәтуллин җитәкләгән тынлы оркестрда уйнаган була. Хорны шунда уйнаган система буенча өйрәтә. Мәктәпләр арасында смотр-конкурслар оештырыла. Бәйгегә җибәргәнче, мәктәп укытучыларына хорны тыңлап карыйлар. Өч тавышка җырлауны берсе дә аңламый. Боларны чыгарып оятка калмабызмы, болардан әллә нинди тавышлар чыга бит диләр. Зөфәр, төрле дәлилләр табып, үз хорын яклап чыга, смотрда чыгыш ясарга рөхсәт ала. Алар конкурста иң соңгы булып җырлыйлар. Жюрида утырган махсус белемле егет, өч тавышка җырлаучы хорны ишетеп, таң кала, беренче урын бары тик аларга ди. Күп еллар беренче булган күрше Димитрово мәктәбенә шулай итеп, алдынгы урын эләкми. Егерме ел дәвамында мәктәп хорына тиңнәр табылмый. Шул елларда Зөфәр Алабуга культура-агарту училищесын, аннан Казан педагогия институтының музыка факультетын тәмамлый. Үзлегеннән бик күп методик дәреслекләрне өйрәнгән әзерлекле егет югары уку йортында бик җиңел укый.

Музыка укыту белән бергә, егет мәктәп ишек алдында хезмәт фәне өчен әзерләнгән йортка да җан кертә. Аны ике өлешкә бүлеп, берсендә – слесарь, икенчесендә столяр эшләре өчен кабинетлар ясый. Укучыларны үзе белгән тимер, агач эшләренә өйрәтә. Шуларга өстәп, Зөфәргә машиноведение дәресе дә укытырга туры килә. Укуны практика белән бәйләп алып бару өчен машина кирәк була. Списать ителгән бер машинаны мәктәп ишек алдына алып кайтып куялар. Бер җыелышта Зөфәр: "Мин бу машинаны җыеп чыгачакмын", – дип әйтеп ташлый. Бу сүзгә укытучылар ышанмый, елмаеп кына куялар. Чаллыда тимер җыюда эшләүче танышына запчастьләр кирәклеген әйткәч, монда бөтен нәрсә дә бар, эзләргә генә кирәк, дигән җавапны ишетеп, Зөфәр бик сөенә. Бер-ике айда машина көпчәкле була. Аннан двигатель, башка детальләр үз урыннарын таба. Бер ел дигәндә, машина йөреп китә. Мәктәп өчен бу көн бәйрәмгә әйләнә. Директорны утыртып, ГАИга номер алырга машина үз ходында бара. Машина Зөфәрнең тормышында да бик булыша. Өй салырга бүрәнәләрне шуның белән алып кайта ул. Бүген яшәгән алты почмаклы өен 1963 елда үз куллары, үз проекты белән салып кора.

Моңа кадәр дә, 1960 елда, биш кеше утырышлы аэрочана ясап, шәһәр халкын шаккатырган була. Шактый вакыт гаилә Бикләнгә шул чана белән кайтып йөри. Чаллыда зур төзелеш башлангач кына, чана-

(Ахыры 6 нчы биттә)

**ГЫЙБРӘТХАНӘ 6**

**(Ахыры. Башы 4-5 битләрдә)**

да йөрүләрен туктаталар. Чөнки бөтен җирдә төзелеш башланып китә, чана белән авылга үтү мөмкинлекләре бетә.

– Бик уйланып эшләнгән чана иде ул. Фотосурәте калмаган шул. Кызыксынсагыз, мин аның сурәтен ясый алам, – дип елмая Зөфәр абый.

– Электросабан да ясады бит ул, – дип, Людмила ханым да әңгәмәгә кушыла. – Аның белән күп еллар бакча җирен эшкәрттек, казыдык әле без...

Минем дә, үз чиратымда, китапханәнең сәнгать бүлеген бизәүче пианиноны, әдәбият тарихы музеенда урын алган балалайка, гармуннарны да Зөфәр абыйның алтын куллары төзәткәнен әйтеп үтәсем килә.

Зөфәр Сәгыйтов нинди генә эшкә алынмасын, эшен җиренә җиткереп башкарып чыга. Гаилә коруы гына бераз икенче планга күчә. Беренче тапкыр 36 яшендә өйләнә. Үз тиңен тапканчы, язмыш аны төрле яклап сыный. 1978 елда ул Людмиланы очрата. Яңа гына Түбән Кама музыка училищесын тәмамлап кайткан яшь белгеч белән ике арада, беренче күрү белән үк, мәхәббәт җепләре сузыла. Эшләре дә бергә, гаиләне дә бергә алып баралар. Берсе – хор белән дирижерлык итеп, икенчесе музыка коралында оста уйнап, бер-берсенең күңелендә урын табалар. Менә инде кырык җиде ел алар бергә гомер кичерәләр, берсен-берсе тулыландырып иҗат итәләр.

Зөфәр абыйның бер зур теләге әлегә тормышка ашмаган. Балалар, оныклар – алар өендә көтеп алынган, яраткан кунаклар. Ул нәселләрендәге барлык туганнарын, балаларын, онык-оныкчыкларын бергә җыярга хыяллана. Бүгенге көндә Сәгыйтовларның дүрт баласы, тугыз оныгы, бер оныкчылары бар.

Балалар, оныклар "дәү әти" дип кенә торалар. Аның янәшәсендәге мөлаем, сөйкемле, игътибарлы ханымга, якын итеп, "дәү әниебез" диеп дәшәләр. Шулай булсын, бергә аңлашып яшәүләргә ни җитә? Сәгыйтовлар гаиләсе бәхетле, матур тормыш юлы узалар. Күпсенмә, Ходаем, бу бәндәләреңнән шушы бәхетне дип кабатлыйм.

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА, Чаллы.**